**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дурт-Мунча авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№58** **22.04.2022 ел.**

**«2021 елга һәм2022-2023 еллар план чорына**
**Зәй муниципаль районының**
**Дурт-Мунча авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турында»**

Зәй муниципаль районының Дурт-Мунча авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 ел өчен Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 5367,5 мең сум, чыгымнар буенча 5411,9 мең сум, чыгымнар керемнәрдән 44,4 мең сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:
1.1. 2021 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;
1.2. 2021 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;
1.3. тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 4нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча 2021 ел өчен бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә расларга.
2. 5 нче кушымта нигезендә Дурт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды хисабына Дурт-Мунча авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында хисапны игътибарга алырга.
3. Карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Дурт-Мунча**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Т. Ситдиков**